# Дару үләннәре







# Зверобой





# Сары мәтрүшкә

Болында, урман аланында үсә. Чәчәкләрен һәм яфракларын файдаланалар. Чәчәк ату чорында җыялар. Салкын тигәннән, ашказаны, эчәк, бавыр, бөер авыруларыннан файдалы.



# Душица





# Гади мәтрүшкә

Болында, урман аланында, бакчада үсә. Чәчәкләрен һәм яфракларын файдаланалар. Чәчәк ату чорында, июльдән сентябрьгә кадәр җыялар. Борчылганда, салкын тигәннән, йокысызлыктан файдалы.



# Земляника





# Каен җиләге

Урман аланында үсә. Җиләкләрен һәм яфракларын файдаланалар. Яфракларын май ахырында – июнь башында, җиләкләрен июнь ахырында – июль башында  җыялар. Ашказаны, бавыр, бөер авыруларыннан, кан басымы югары булганда файдалы.



# Большой подорожник





# Зур бака яфрагы

Чәчәк ату чорында, җәй буе җыялар. Ашказаны - эчәк,  авыруларыннан, яра, җәрәхәтләрне төзәтү өчен файдалы. Юл буйларында үсә. Яфракларын файдалананалар.



# Тысячелистник






# Меңьяфрак

Болында, агачлыкта, бакчада үсә. Чәчәкләрен һәм яфракларын файдаланалар. Чәчәк ату чорында июль ахырыннан көзгә кадәр җыялар. Ашказаны - эчәк авыруларыннан файдалы.



# Мать-и-мачеха





# Үги ана яфрагы

Елга буйларында үсә. Чәчәкләрен һәм яфракларын файдаланалар. Чәчәкләрен чәчәк ату чорында, яфракларын җәйнең беренче яртысында җыялар. Салкын тигәннән, бронхиттан, үпкә авыруларыннан, ютәлдән файдалы.



# Полынь горькая





# Ачы әрем

Болында, урман аланында үсә. Яфракларын файдаланалар. Чәчәк атканчы җыялар. Аппетитны яхшырту өчен, ашказаны, бавыр, бөер авыруларыннан файдалы.



# Ашказаны – эчәк авыруларыннан

- *Ачы әрем*
- *Меңьяфрак*
- *Зур бака яфрагы*
- *Каен җиләге*
- *Сары мәтрүшкә*



# Бөер авыруларыннан

- *Каен җиләге*
- *Ачы әрем*



# Бавыр авыруларыннан

- *Ачы әрем*
- *Каен җиләге*



# Салкын тигәндә

- *Гади мәтрүшкә*
- *Сары мәтрүшкә*
- *Үги ана яфрагы*



# Яра, җәрәхәтләрне төзәтү өчен

- *Зур бака яфрагы*



# Йокысызлыктан

- *Гади мәтрүшкә*



# Табиб киңәшләре

Онытмагыз:

- дару үләннәрен яхшы белеп җыярга;
- дөрес киптерергә;
- табиб белән киңәшеп кулланырга;
- шәһәрләрдән, заводлардан, юллардан ерак урыннардан гына җыярга;

